СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**«18» июль 2017 ел** **№ 133**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2015 елның 26 октябрендәге 112 номерлы Арча район Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2016 елның 10 ноябрендәге 76нчы номерлы үзгәрешләр белән)**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 23 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Арча район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәнең 12 пунктында түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча белән тулыландырырга:

«9) муниципаль хезмәтне биләүне дәгъвалаучы Россия Федерациясе гражданы тарафыннан һәркемгә ачык мәгълүмат, шулай ук аны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматлар урнаштырылган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның битләре турында белешмәләр».

2. Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында аерым вазыйфаи затлар алмашынуга бәйле рәвештә Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Арча муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе вазыйфасын биләгән Абдуллин Фоат Минзиевичны чыгарырга;

- Арча муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе вазыйфасын биләгән Гарипов Роберт Радиковичны кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (http://arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев